ГЛАВА СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

УРТА КАМЫШЛА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Урта Камышлы ав.

КАРАР

«5» ноябрь 2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы торак пунктында Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Кече Камышлы авылы, К.Маркс урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан Кече Камышлы авыл клубында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Декабристлар урамы 1-38нче, К.Маркс тыкрыгы 1нче йортта яшәүче гражданнар Җыенының беренче этабын 2020 елның 18 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы торак пунктында Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Кече Камышлы авылы, К.Маркс урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан Кече Камышлы авыл клубында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча К.Маркс урамы 1-67нче йортларда яшәүче гражданнар Җыенының икенче этабын 2020 елның 18 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Кече Камышлы авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлү тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

1. Су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару;
2. Балалар уен мәйданчыгы сатып алу;

3. Кече Камышлы торак пункты чикләрендә эчке торак юлларын ремонтлау».

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Кече Камышлы авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы А.В. Яманов